**Совет**
**Алешкин-Саплыкского**
**сельского поселения**
**Дрожжановского муниципального**
**района Республики Татарстан**

**Татарстан Республикасы**
**Чүпрәле муниципаль районы**
**Алешкин-Саплык**
**авыл җирлеге**
**Советы**

**422478, Россия, Республика Татарстан, Дрожжановский район, с. Алешкин-Саплык, ул. Школьная, д.3а**
**тел. (84375) 37-5-35, 37-5-49, факс. 37-5-36**
**E-Mail: AlSap.Drz@tatar.ru**

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

Алешкин-Саплык

25 февраль 2021 ел № 9/2

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Алешкин-Саплык авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турындагы «Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында" 2020 елның 26 декабрендәге 96-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы нигезендә, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Алешкин-Саплык авыл җирлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Алешкин-Саплыкавыл җирлеге Советы КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Алешкин-Саплык авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Алешкин-Саплык авыл җирлеге Советының 26.02.2020 ел, № 69/2 карары (04.06.2020 ел, № 72/2, 13.11.2020 ел, № 4/2 редакциясендә) белән расланган Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр не кртергә:

**6 статьяның 22 пунктында** «хезмәт кенәгәсе" сүзләреннән соң "(булган очракта)» дигән сүзләр өстәргә;

**13 статьяның 3 пунктындагы 4 пунктчасында** «хезмәт кенәгәсе» сүзләреннән соң «һәм (яисә) законнарда билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән хезмәт эшчәнлеге турында белешмәләр " сүзләрен өстәргә»;

**20 статьяның 2 пунктындагы 4 пунктчасын** түбәндәге яңа редакциядә бәян итәргә:

«4) муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт кенәгәләрен алып бару (булганда), муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан муниципаль хезмәт узган чорда хезмәт эшчәнлеге турында мәгълүматлар формалаштыру һәм әлеге

белешмәләрне мәҗбүри пенсия иминияте системасында индивидуаль (персональләштерелгән) исәпкә алу турында Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә, Россия Федерациясе Пенсия фондының мәгълүмат ресурсларында саклау өчен бирү;».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Алешкин-Саплык авыл җирлеге сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар, гамәлдәге законнарда билгеләнгән башка срокларда үз көченә кергән нигезләмәләрдән тыш, рәсми басылып чыккан көнендә үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Чүпрәле
муниципаль районы Алешкин-Саплык
авыл җирлеге Башлыгы: П.Н.Артемьев